Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район Советы

**КАРАР № ХХ-8**

Балык Бистәсе штп. 2017 елның 24 июле

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы милкендәге җир кишәрлекләре белән бүлеп бирү нәтиҗәсендә хосусый милектәге җир кишәрлекләре мәйданын арттырган өчен түләү күләмен билгеләү тәртибен раслау турында

Россия Федерациясе Җир кодексының 39.28 маддәсендәге 5 пункты, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы милкендәге җир кишәрлекләре белән бүлеп бирү нәтиҗәсендә хосусый милектәге җир кишәрлекләре мәйданын арттырган өчен түләү күләмен билгеләүнең кушымта итеп бирелә торган Тәртибен расларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

3. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
район Советы рәисе И.Г. Вәлиев

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
район Советының
2017 елның 24 июлендәге
ХХ-8 номерлы карары
белән расланды

**Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы милкендәге җир кишәрлекләре белән бүлеп бирү нәтиҗәсендә хосусый милектәге җир кишәрлекләре мәйданын арттырган өчен түләү күләмен билгеләү ТӘРТИБЕ**

1.Бу Тәртип Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль милкендәге җир кишәрлекләре белән бүлеп бирү нәтиҗәсендә хосусый милектәге җир кишәрлекләре мәйданын арттырган өчен түләү күләмен билгеләү кагыйдәләрен (алга таба-түләү күләме) тәгаенли.

2.Түләү күләме Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы тарафыннан исәпләнә.

3. Түләү күләме Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы милкендәге җир кишәрлегенең кадастр бәясенең 100 проценты дип билгеләнә, җир кишәрлекләре белән бүлешү нәтиҗәсендә шәхси милеккә тапшырылырга тиешле мондый җир кишәрлеге мәйданына пропорциональ исәпләнә, әлеге Тәртипнең 4 пунктында каралган очрактан гайре.

4. Муниципаль ихтыяҗлар өчен җир кишәрлекләрен алу максатыннан җир кишәрлекләре бүлеп бирелгән очракта түләү күләме җир кишәрлекләрен бүлү нәтиҗәсендә шәхси милеккә тапшырылырга тиешле Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль милкендәге җир кишәрлегенең базар хакының бәяләү эшчәнлеге турындагы законнар нигезендә билгеләнә.